Казан
(Идел буе)
федераль
университеты
газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№11
(141)

18 июнь
2015 ел



prav.tatarstan.ru

# Чал тарихлы дөньяны ачып...



Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк, диләр. Тарихка сакчыл караш булганда гына, мәгариф, фән, техника дөньясында әһәмиятле ачышлар ясала. Татарларның тарихи ватаны саналган Болгар җирендә яңа фәнни-гамәли комплекслар ачылу, абруйлы кунакларның университет тарихы белән кызыксынулары – болар барысы да милләт, дәүләт үсеше өчен тарихның никадәр мөһим булуын күрсәтә.



prav.tatarstan.ru

# Чал тарихлы дөньяны ачып...

**14 нче июньдә Болгар дәүләт тарих һәм архитектура музей-тыюлыгында «Болгар шәһәренең урта гасырлар һөнәрчелеге» дип исемләнгән фәнни-гамәли комплекс ачылды.**

Әлеге проектка 2014 нче елда Татарстан Республикасы президенты **Рөстәм Миңнеханов** йөкләмәсе белән нигез салына. Комплекс төзелешенә Казан федераль университеты галимнәре, «Яңарыш» фонды экспертлар советы җитәкчесе **Илшат Гафуров**, ТР Фәннәр Академиясенең А.Х.Халиков исемендәге Археология институты, Болгар дәүләт тарих һәм архитектура музей-тыюлыгы һәм «Яңарыш» фонды үз өлешләрен керттеләр.

Ачылыш тантанасы барышында ТР президенты вазыйфаларын башкаручы Р.Миңнеханов Халыкара кыр археологиясе мәктәбендә кунакта булды.

Болгар шәһәрчегендә табылган казылмалар һәм Алтын Урда чорына караган хатын-кыз баш киеме музей карамагына тапшырылды.

Көн дәвамында тимерчелек, зәркән эшләнмәләре, пыяла ясау буенча һөнәрчеләр үзләренең осталыгын күрсәттеләр.

Урта гасырларда Болгар сату-алу, һөнәрчелек, шәһәр тормышын алып бару буенча иң алга киткән өлкәләрнең берсе, Евразия мәдәниятләренең үзара аралашуын көйләп торучы үзәк була. «Болгар шәһәренең урта гасырлар һөнәрчелеге» комплексы шушы үзенчәлекләрне искә алып ясалган.

Фәнни-гамәли комплекс төзекләндерү һәм эксперименталь археологик лаборатория, Халыкара кыр археологик мәктәбе, археологик мирасыбызны тәҗрибәләр юлы белән өйрәнүгә юнәлдерелгән остаханәләрдән гыйбарәт. Ул ел дәвамында БДБ һәм ерак чит илләрдән 200дән артык галим һәм 80000ләп турист кабул итәр дип көтелә.

● Бездә кунак бар

# Бездә кунакта - кытай җитәкчелеге

**Казан (Идел буе) федераль университеты Кытай Халык Республикасыннан килгән абруйлы вәкилләрне кабул итте. Халык вәкилләренең Бөтенкытай җыелышы Даими комитеты рәисе Чжан Дэцзян җитәкчелегендәге әлеге делегацияне Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов озатып йөрде.**



Инна Басыйрова фотосы

Абруйлы кунакларны КФУ ректоры **Илшат Гафуров**, тышкы элемтәләр буенча проректор **Линар Латыпов** һәм университетта укучы Кытай студентлары каршы алды.

**Чжан Дэцзян** Казан университеты тарихы Музееның экспозицияләре белән танышты. Юридик факультет студентлары, шул исәптән Владимир Ленин укыган чордан, ягъни 1887 елдан ук үзгәрешсез сакланган 7 нче аудитория белән танышкач, КХР Парламенты башлыгы, уку йорты тарихына хезмәткәрләр тарафыннан шундый игътибарлы мөнәсәбәт, сакчыл караш күрсәтелүенә соклануын белдерде.

Очрашу ахырында, киләчәктә хезмәттәшлекнең тагын да үсәчәгенә өметләр баглап, һәр як үзенең истәлекле бүләкләрен тапшырды.

Шуны әйтергә кирәк: КФУ Кытай Халык Республикасының мәгариф һәм фән үзәкләре белән актив багланышта тора. Казан университетының партнерлары арасында Шанхай астрономия обсерваториясе, КХР Фәннәр академиясенең Милли астрономия обсерваториясе, Синцзянь университеты, Хунань, Нанкий һәм Гуан педагогик университетлары, Пекин халыкара укыту университеты һ.б. бар. Моннан тыш, КФУ базасында Конфуций институты уңышлы эшләп килә.

Университетыбызны һәм Кытай Халык Республикасын, үзара академик алмашулардан тыш, башка уртак проектлар булуы да якынайта. Мисал өчен, «Кояш системасының кечкенә җисемнәрен күзәтү һәм өйрәнү» дип аталган халыкара фәнни проект кысаларында КФУ Шанхай астрономия обсерваториясе белән, шулай ук IMCCE Күк механикасы институты (Франция), Төркия астрономия обсерваториясе (ТЮБИТАК) һәм Николаев астрономия обсерваториясе (Украина) белән берлектә фәнни-тикшеренү эшләре алып бара.

2015 елның апрелендә КФУның Яр Чаллы институты Haier компаниясенең Укыту үзәген ачып җибәрде. Haier компаниясе кытай базарында техника брендларының иң эресе санала. Haier Укыту үзәгендә студентларга гына түгел, квалификацияне үстерү максатыннан чыгып, проектлаштыру, монтаж, техник хезмәт күрсәтү өлкәләре белгечләренә дә белем бирәләр. Монда белем алучылар техника дөньясындагы яңа ачышлар, Haier җайланмаларының перспектив модельләре белән дә танышып бара.

Кыскасы, хезмәттәшлек Казан университеты өчен дә, кытайлылар өчен дә файдалы!

● Гыйльми совет

# Кече предприятие эшчәнлеген ничек яхшыртырга?

**Илмир ВӘЛИЕВ,** Математика һәм механика институты

**Казан (Идел буе) федераль университеты Гыйльми советы 11 июньдә булып узган чираттагы утырышында инновация эшчәнлегенең торышы, аерым алганда, университеттагы кече предприятиеләр эшенең нәтиҗәлелеген тикшерде.**

Утырыш котлау һәм бүләкләүләрдән башланып китте. Иң элек ректор **Илшат Гафуров** коллегаларын Россия көне белән тәбрик итте. Алга таба ул «Россия Федерациясе югары һөнәри белем бирүнең мактаулы хезмәткәре» исеменә лаек булган университет хезмәткәрләренә танныклыклар һәм күкрәк билгеләре тапшырды. Берничә кеше РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының мактау грамоталары белән бүләкләнде.

Алга таба Гыйльми совет утырышы гомуми мәсьәләләргә күчте: кафедра мөдирләре сайланды, гыйльми дәрәҗәләр бирелергә тиешле нәмзәтләр исемлеге тавышка куелды.

Утырышта инновацион эшчәнлекнең узган елгы нәтиҗәләренә аеруча зур игътибар бирелде. Бу хакта тулырак мәгълүмат инженерлык эшчәнлеге буенча проректор **Наил Кашапов** докладында чагылыш тапты. Инновация юнәлеше үсешенең бер тармагы булып, кече инновация предприятиеләре эшчәнлеге тора. Бүгенге көндә КФУда аларның саны 45-кә тула. Проректор сүзләре буенча, КФУның инновацион инфраструктурасы объектларының комплекслы үсеш программасында язылган максатларга университет тулаем ирешкән. Ә инновацион проектларны тормышка ашырудан югары уку йорты 90 миллион сум тирәсе керем алган.

Утырыш барышында әлеге предприятиеләрдән кайберләренең, формаль күрсәткечләр планын үтәү максатында ачылганлыктан, түбән табыш белән эшләве ассызыкланды. Моңа җавап итеп, проректор татар халкының «Беттән бет туа» дигән мәкале белән акланырга тырышты.

Ректор Илшат Гафуров мондый акланунын урынсыз булуын белдерде. Әйтеп кителгән уңай күрсәткечләргә карамастан, кече предприятиеләрнең эшен кискен җайга саласы бар. Ректор фикеренчә, кече предприятиеләр эшчәнлеген өч күрсәткеч белән бәяләп була. Аның беренчесе – интеллектуаль милек күләме, икенчесе – университетны тәмамлап, инновацион предприятиеләр структурасында эшкә калган белгечләр саны. Өченче күрсәткеч булып, предприятиеләрнең уку йортына китергән керем күләме тора. Димәк, киләчәктә шушы өч юнәлеш буенча эшчәнлекне камилләштерергә кирәк булачак.

Университет структурасындагы үзгәрешләргә килгәндә, Фундаменталь медицина һәм биология институты (ФМһБИ) составына Физик культура һәм спорт институтының (ФКһСИ) берничә кафедрасы кушылачак. Бүгенге көндә ФКһСИда барлыгы 4 кафедра бар. Тәкъдим ителә торган проект нигезендә шуларның өчесе ФМһБИның физик культура бүлегенә керер дип көтелә. Ә адаптив физик культура кафедрасы, анатомия, физиология һәм кешенең сәламәтлеген саклау кафедрасы белән берләшеп, биология һәм биотехнологияләр бүлегенә күчәчәк.

ФМһБИ директоры Андрей Киясов сүзләре буенча, кушылу сәбәпле барлыкка килгән физик культура бүлегенең төп эшчәнлеге булып тернәкләндерү медицинасы белгечләре һәм паралимпия спорты өлкәсендә эшләүче тренерлар әзерләү торачак. Ә 2016 елның сентябреннән спорт дисциплиналары кафедрасы инклюзив физик культура һәм паралимпия спорты кафедрасы итеп үзгәртеләчәк.

Алар арасында тормыш куркынычсызлыгы һәм гомуми физик әзерлек кафедрасы да бар. Бу кафедралар нигезендә гомумуниверситет күләмендә хәрби кафедра оешачак.

КФУның МВА Югары мәктәбе КФУның Югары бизнес мәктәбе буларак үзгәртелә. Киләчәктә әлеге мәктәпкә Читтән торып уку һәм профессиональ әзерлек үзәгендә белем алучы студентлар күчереләчәк.

Тел институты бүгенге көннән Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты составында яши башлый.

Физика институтында да үзгәреш көтелә: физикада белем бирү технологияләре һәм физиканы укыту теориясе һәм методикасы кафедралары берләшәчәк.

• 14 июнь – дөньякүләм кан донорлары көне

# Яшәргә өмет бир – донор бул!

**Ландыш ВӘЛИЕВА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты



2005 елның маенда, Бөтендөнья сәламәтлек саклау ассамблеясы вакытында, төрле илләрнең сәламәтлек саклау министрлары 14 июньне дөньякүләм кан донорлары көне итеп билгеләргә, дигән фикергә килгәннәр. Ә 20 апрельдә Россиядә иҗтимагый мөһим бәйрәмнәрнең берсе – Милли донор көне билгеләнә. Бу көн, беренче чиратта, донорларга – бөтенләй таныш булмаган кешеләрнең сәламәтлеге һәм яшәү дәвамлылыгы өчен үз каннарын түләүсез биргән кешеләргә багышлана.

Акциянең максаты – кан тапшыру эшенә күбрәк кешеләрне тарту, алыштыру өчен ышанычлы кан һәм аның компонентларының әһәмиятен аңлату, республиканың сәламәтлек саклау өлкәсендә ирекле кан донорларының керткән өлешләрен билгеләү һәм бу эштә катнашы булган кешеләргә рәхмәтләр белдерү.

14 июньне шулай билгеләп үтү Австрия иммунологы һәм врачы, Нобель премиясе лауреаты, кан тапшыруда донорлыкны беренче уйлап тапкан һәм аңа нигез салган Карл Ландштейнер (1868-1943) хөрмәтенә кабул ителә. Бу чарада барлыгы 193 дәүләт, 181 Кызыл Хач һәм Кызыл Ярымай милли җәмгыяте вәкилләре, 50гә якын үз теләкләре белән донор булып торучы төрле оешма, хәрәкәтләр катнаша. Кан бирү акцияләре һәр елны билгеле бер чакыру белән чыга. 2013 елда «Яшәргә өмет бир – донор бул!», 2014 елда – «Әниләрнең тормышын саклап калу өчен – хәвефсез кан» дип аталса, 2015 ел «Кеше гомерен саклап кал!» дигән шигарь астында үтә.

Яңа ел алдыннан «Мин – Татарстан доноры» акциясе старт алган иде. Әлеге проект «Без...» яшьләр хәрәкәте проекты, Татарстан Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Иҗади яшьләр академиясе һәм Татарстан Сәламәтлекне саклау Республика кан тапшыру үзәге булышлыгында тормышка ашырыла. Акциядә беренче тапкыр каннарын тапшырган һәм донор картасы алган шәһәр студентлары катнашты.

Казан федераль университетында, кеше тормышын коткарып калу максатыннан, актив студентлар оештырган донорлар белән эшләүче махсус волонтерлар хәрәкәте бар. Бу чарада катнашырга теләгән һәр студент, берникадәр кан биреп, кемнең дә булса тормышын коткарып калуга үз өлешен кертә ала.

**Рәмзия Шәкүрова** КФУның Фундаменталь медицина һәм биология институтының 4 курсында белем ала. Ул инде дүрт тапкыр донор булырга өлгергән. «Кан тапшырыр алдыннан махсус медицина тикшеренүе үтәргә туры килә, шулай ук донорлыкка каршы килердәй берничә авыруны да истән чыгармаска кирәк: ВИЧ-инфекция, сифилис, вируслы гепатит, туберкулез, кан чирләре, онкология авырулары һ.б. Донорлык турында төрле мифлар да йөри. Аларның берсенә дә ышанмагыз. Иң мөһиме, «ул миңа кагылмый» дигән сүзләрдән ерак торыгыз, чөнки теләсә кайсы кешегә уйламаганда кинәттән кан кирәк булуы ихтимал. Статистик мәгълүматларга караганда, һәр өченче кеше үз гомерендә кан алыштыруга дучар була. Шуңа күрә сез дә, донор булып, башкаларга ярдәм итә аласыз», – ди ул.

Кан бирүчеләр гомерләрендә дә күрмәгән кешеләргә ярдәм итә, ә кайчакта үлем тырнагыннан да йолып алып кала. Россиядә кан донорлары проблемасы әлегәчә тулы хәл ителмәгән. Илдә лейкоз, гемофилия белән авыручылар, гадәттән тыш хәлләрдә, юл фаҗигаләрендә зыян күрүчеләр, бала тапканда күп кан югалткан аналар, кан салуга мохтаҗ яңа туган сабыйларның гомерен саклап калуда донорларның ярдәмен берни белән дә алыштырып булмый.

• **Факт:** 14 июньдә, Бөтендөнья донорлар көнендә, Казанда республика кан бирү станциясендә кан бирү акциясе узды. Станцияләрдә ирекле кан бирүчеләрне Донор көнендә генә түгел, теләсә кайсы көнне көтәләр. Сүз уңаеннан, Универсиада волонтерлары 2013 елда 2013 литр кан бирү бурычын үтәде.



## Изге Рамазан ае мөбарәк булсын, хөрмәтле дин кардәшләребез!

**Мөселманнарда 18 нче июнь** – Рамазан аеның беренче көне. Бу – сабырлык, түземлек, шәфкатьлелек, игелек ае. Бу айда, ашказанын барлык ризыктан мәхрүм итеп, кояш чыкканнан кояш батканга кадәр ураза тотыла, тәмәке тарту, хәмер эчү, якынлык кылу тыела. Ачуланышу, гайбәт сөйләшү шулай ук зур гөнаһ санала. Гомумән алганда, бары тик изге гамәлләр генә кылырга кирәк. Дөрес, яхшы гамәлләр Рамазан аенда гына түгел, һәр көнне башкарылырга тиеш, әмма бу изге ай аерым урын алып тора, моны һәр мөселман кешесе белергә тиеш. Тоткан уразаларыбыз кабул булсын!

• Сораштыру

# «Көндәлекләр ялгыз языла да, көндәлекләр ялгыз укыла...»

**Алисә ӘХӘТОВА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Элек-электән кызларның бик күбе, кайчак егетләр дә, көндәлек язу белән мавыккан. Башкалар белән уртаклашу читен булган хис-кичерешләр, тойгылар, көндәлдән ташып, дәфтәр битендә чагыла. Йөрәк түрендә йөрткән иң яшерен сүзләр, алдагы көнгә якты хыяллар, уй-фикерләрең шәхси көндәлекләрдә урын ала. Ләкин хәзерге заманда яшьләр арасында бу күренеш сирәк очрый. Күпләр моны вакыт булмау, эш күплеге белән аңлата.

«Хат терапиясе» өлкәсендәге белгеч, АКШның Техас университетының психология фәннәре профессоры Джеймс Пеннебэйкер фикеренчә, шәхси көндәлекләр – сәламәтлекне ныгытуның иң нәтиҗәле ысулы. Кичерешләрен кәгазь битенә төшергәннән соң, кешенең йөрәк тибеше җайлана, кеше үзен ял иткән кебек хис итә.

Атнасына кимендә 4 тапкыр 20 шәр минут кичерешләреңне, уй-фикерләреңне, көндәлек вакыйгаларны дәфтәр битенә язарга киңәш итә галим. Ләкин әлеге шәхси дәфтәрне сезнең үзегездән башка беркем дә укырга тиеш түгел. Читләрнең сезнең көндәлеккә күзе төшү белән, бөтен тормышыгыз үзгәрергә мөмкин. Шуңа күрә шәхси уйларыгыз салынган дәфтәрегезне яшерен урыннарда саклагыз, аны ялгызыгыз калганда гына языгыз.

Хәзерге көндә яшьләр көндәлекнең нәрсә икәнен беләләрме? Үзләре белән булган вакыйгаларны кәгазьгә төшерәләр микән? Бу турыда студентлардан сораштым.

• **Алсу Нургатина, Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты:**

Көндәлекне мәктәп елларыннан бирле язам. Беренче серләремне дус кызларыма сөйләсәм, аннан акрын гына дәфтәр битенә яза башладым. Тора-бара, дәфтәрләрнең барысын бергә җыеп, зур дәфтәр ясадым. Киләчәктә, 16 яше тулгач, кызыма бүләк итәргә ниятлим. Көндәлегемдәге язмалар акрын гына үзем иҗат иткән әсәрләремә дә күчә.

• **Рамилә Мансурова, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты:**

Беркайчан да язып караганым булмады. Миңа калса, тыныч холыклы, сабыр кешеләр генә көндәлек язарга сәләтледер. Ә мин андый түгел, түземлегем җитмәс иде. Әмма дусларым арасында көндәлек язучылар бар.

• **Рания Абдуллина, Фундаменталь медицина һәм биология институты:**

Дусларым арасында берничә кешенең язганын беләм, ләкин үземнең көндәлек язганым юк. Бөтен кирәкле мәгълүматны гаджетта саклыйм. Көндәлек алып бару өчен, минемчә, матур һәм аңлаешлы язу сәләтенә дә ия булырга кирәктер, хәтта үзең өчен генә язсаң да. Ә мин язарга яратмыйм.



• **Динә Шәкүрова, Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты:**

Көндәлек ул – көн дәвамында башкарган эшләреңне бәйнә-бәйнә язып бара торган бик калын дәфтәр, кайчакта көнелеңне бушатырлык якын дус, сер сандыгы да. Мәктәптә укыган чакта, көндәлек алып бара идем, хәзер моның кирәген тапмыйм. Өстәвенә, көне буе язу эшендә булгач, шуңа өстәп тагын көндәлек тутырып утырырга теләк тә, вакыт та калмый. Танышларыма килгәндә, алар арасында да бу шөгыль белән мавыгучылар юк дип беләм.

• **Алсу Фәрзиева, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты:**

Шәхси көндәлекләр турында ишетеп беләм, кызганычка каршы, үземнең язып караганым булмады. Андый эш белән мавыгыр өчен, ялгызың гына калу кирәктер, ә мин ялгызым гына калуны өнәмим. Аралашырга яратам, шуңа күрә вакытны дусларым, туганнарым белән сөйләшеп, аралашып үткәрәм.

• **Гөлназ Гаделҗанова, Экология һәм табигатьтән файдалану институты:**

Көндәлек язу белән мавыкмыйм. Ләкин көн саен һава торышын язып барам да, алдагы еллардагысы белән быелгысын чагыштырам. Моны мин укырга кергәч эшли башладым, үзләштерелә торган һөнәремә бәйле булганга шулай эшлимдер, бәлки.

• **Гүзәл Мәхмүтова, Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты:**

Озак вакытлар көндәлек алып барганым булды, аннан, аны сеңлем табып укыгач, башка язмаска булдым. Серeңне синнән ары тагын бер кеше белсә дә, бу инде сер булмый. Ә көндәлек алып бару бик файдалы. Фикерләрнең теркәлеп, уйларның язылып баруы бик мөһим. Танышларым арасында да көндәлек алып баручылар шактый. Хәтта егетемнең дә шәхси көндәлеге бар. Кайвакыт нәрсә язылганын бик тә беләсе килсә дә, тыелып калырга туры килә, намус борчый. Шәхси әйбер барыбер шәхси булып калырга тиеш, минемчә.

• **Гүзәл Асылова, Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты:**

Яшүсмер вакытта көндәлек язгалаганым булды. Ләкин гел түгел. Укуда төрле мәшәкатьләр очраса, дус кызларым янәшәмдә бумаганда, көндәлек язу белән мавыга идем. Ләкин бу эш белән соңгы елларда шөгыльләнгәнем юк. Бәлки, вакыт җитмидер, бәлки, аралашу күбрәктер. Дусларым арасында көндәлек язучыларны белмим.

Влад Михневский фотосы

● Уңыш сере

# Айзат Шәймәрданов: «Журналистларга бунтарьлык җитми»

Журналистика – иҗади һөнәр. Әлеге бүлеккә укырга керүчеләр юкка гына иҗади конкурс аша узмый. Айзат Шәймәрданов – шундый үзенчәлекле иҗади кешеләрнең берсе. Ул – газетада да, телевидениедә дә эшләүче кыю, үткен журналист, гаделлек эзләүче, кыерсытылганнарны яклаучы, ярдәмгә килергә әзер торучы шәхес. Шуның белән беррәттән, ул әле КФУның өченче курс аспиранты да.

**Ләйсән ГЫЙМАЛЕТДИНОВА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

**– Айзат, ни өчен тормышыңны журналистика белән бәйләргә булдың?**

- Бу минем табигатемә хастыр. Күп нәрсәгә үз карашым, позициям бар. Мин, гадәттә, азчылык ягында. Чөнки күпчелек төрле пропагандистик каналлар сөйләгәнчә, алар кушканча гына уйлый. Ни кызганыч, халыкның үз фикере юк. Бер генә мисал. 1991 елда СССРны саклау буенча бөтенсоюз референдумында халык хуплап тавыш бирә. Әмма ел ахырында, зур дәүләт юкка чыккан вакытта, әлеге дә баягы бу халык СССРны яклап ни сүзен әйтмәде, ни урамга чыкмады. Иманым камил, әгәр иртәгә Советлар Союзына кайтырга телисезме, дип агитацияләсәләр, халык йөгереп барып тавыш бирәчәк. Шундый ясселыкта уйлау мине башкалардан аерып торадыр.

Әмма кечкенәдән журналистикага кереп китәрмен дип уйламадым да. Мәктәптә укыганда, сыйныфтагы яхшы иншаларны укытучыбыз район газетасына бирә иде. Шулар аркасында бишенче-алтынчы класста газета белән хезмәттәшлек башланды.

**- Журналистика бүлегендә укыганда, иң истә калган мизгелләр.**

- Алар бик күп. Безнең факультетның үз традицияләре бар бит.



Фото Айзат Шәймәрданов архивыннан

Ел саен беренче курс студентлары өчен «Багышлау» бәйрәме була. Ул табигать кочагында ур-манда үткәрелә. Безнең курс шул хәтле дус һәм шаян булды, без бу чарада укытучыларга пародия күрсәтә идек. Мин шәхсән Илһам Фәттахов һәм кайвакыт кафедра мөдире Васил Гарифуллин ролен уйный идем. Бәлки, арттырулар да булгандыр. Әмма бу безне якынайта, берләштерә иде.

**- Син журналистикага спорт темасы белән килеп кердең.**

- Элек спорт темасына гашыйк идем. Бу өлкәне һәрвакыт күзәтеп, өйрәнеп бардым, үзебезнең командалар өчен җан аттым. «Шәһри Казан»да, «Безнең гәҗит»тә эшләгәндә, спортка кагылышлы үз фикерләремне җиткерергә тырыштым. Хәзер бу тема белән гомумән кызыксынмыйм, күп вакытны ала торган өлкә дип саныйм, моңа сөенәм дә, чөнки мондый темаларны баш миен томалаучы нәрсәләр дип кабул итәм. 11нче сыйныфта дин, сәясәт белән кызыксынуым артты. Бүгенгә кадәр әлеге тема белән мавыгам.

**- Язмаларың өчен тәнкыйтьләгәннәре бармы?**

- Әллә ни юк. Судка бирәбез дип янаганнары гына бар, ләкин бу бит сыйфатсыз материал чыканын аңлатмый. Димәк, минем фикер белән кемдер килешми дигән сүз. «Безнең гәҗит»тә эшләгәндә, бер тапкыр судка бирделәр. Материалны мин журналист этикасына һәм хокукый нормаларга тугры калып эшләгән идем. Каршы як мине ялган сүз сөйләүдә гаепләде. Әмма судта без җиңеп чыктык.

**- Айзат, без сине хәзер телевизион журналист буларак беләбез. Бу өлкәгә ничек килеп эләктең?**

- Университетны тәмамлаган елны безнең курстан берничә кешене кастингта катнашырга җибәрделәр. Кызык өчен генә барып карарга булдым. Бер айдан соң шалтыратып, кастингны үттең, дип хәбәр иттеләр. Шулай итеп, телевидение журналистикасын үзләштерә башладым.

**- Телевидениедә беренче сюжетыңны хәтерлисеңме?**

- Хәтерлим. Мине Питрәч Сабантуена җибәрделәр. Анда баргач, үземне журналистика дөньясында яңа кеше итеп хис иттем. Моңа кадәр газетада эшләп, телевидение тормышын, эчке кухнясын бөтенләй белмәгәнемне аңладым. Ничек төшерергә? Ничек эшләргә? Шундый сораулар баштан чыкмады. Бер кинолык материал җыелды, ахырдан бер минутлыкка калдырып, кыскартып бетерделәр. Үземә беренче сюжет бер дә ошамады. Оештыру эшләре күп, техник яклары катлаулы иде. Әмма бу вакыт эше генә булды, тиз арада телевидениегә ияләндем.

**- Хәзер кайсы темаларга өстенлек бирәсең?**

- «Хәбәрләр»дә эшләп, төрле темаларны яктыртырга туры килсә дә, миңа сәясәт, тарихи тармакта эшләү күпкә кызыграк. Узган ел да, быел да сайлау темасыннан баш чыккан юк. Әмма соңгы елларда Татарстан президентының исемен саклау буенча сюжетлар эшләү – минем өчен иң кызысы. Сәяси, юридик яктан бәя бирергә тырышам, халыкның фикерен дә яктыртам.

**- Алай булгач, синеңчә телевидение журналисты нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?**

- Аннан вакыйганы ничек бар, шулай күрсәтү таләп ителә. Гади телдә һәм вакыйганың әһәмиятен җиткерә алсаң, син журналист. Моның өчен сизгер, оператив булу, теманы белү кирәк. Журналист җилнең кайсы яктан искәнен аңларга тиеш. Сорауларны дөрес, кыска һәм аңлаешлы итеп бирү зур роль уйный. Танылган журналист Алексей Венедиктов әйткәнчә, журналист әңгәмәдәшенә гел оппонент булырга, каршылыкта торырга тиеш. Без, татар журналистларына, салкын карашлы булу, һәрнәрсәне үз исеме белән әйтү җитми. Болай дисәк, начар булмасмы, тегеләй әйтсәм, ачуланмаслармы, дип уйлаучылар күп. Хәтта урлаган кешегә дә карак дип әйтергә куркалар. Бунтарьлык җитми. Шәхсән үзем кешеләрне кызырып җибәрергә, эмоцияләрен тышка чыгарырга яратам.

● 14 июнь – Халыкара блогерлар көне

# Татар блогларының сулышы

**Линар ЗАКИРОВ**, Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Рус блогосферасында бүгенгә 1 миллион 150 мең блог исәпләнә, әмма шуларның нибары 46 проценты гына даими яңартыла. MASMI Russia онлайн хезмәтенең берничә ел элек үткәргән сораштыруыннан күренгәнчә, 18,5% укучы өчен блоглар сәяси, икътисади һәм мәдәни өлкәләрдә яңалык чыганагы булып тора. Икенче урында – блогларның мәгълүмати функциясе, ә кызыклы шәхесләр турындагы хикәятләр өченче урында.

Рус телле блогларның барлыкка килү тарихы «Тере Журнал» – LiveJournal.com блог сервисына бәйле. 1998 елда 18 яшьлек Америка студенты, программист Брэд Фицпатрик, интернетта көндәлек язулары алып бару өчен программа язган, аның нигезендә дусларына вебкушымта да ясап биргән. Әмма Фицпатрик LiveJournal шулкадәр уңыш казаныр дип башына да китермәгән. 2002 елда блог сервисы башка телләргә тәржемә ителеп, 2006 елның октябрендә рус телендә дә эшли башлаган.

«Яндекс» статистикасы буенча, рус телле блоглар нигезендә 14 блог-сервиста алып барыла, алар арасыннан «зур өч-лек»не аерып чыгаралар (50 меңнән алып 350 меңгә кадәр көндәлек) Livejournal.com, Diary.ru һәм Blogs.mail.ru.





Болар тупламасында татар телендәге берничә блогка гына тап булдык – rafiskashapov.livejournal.com һәм 1000kvmm.livejournal.com, Diary.ru сайтында тагын икәү – nuria88.diary.ru, rafiskashapov.diary.ru, ә 2014 елның 3 мартында Blogs.mail.ru сайтының эшчәнлеге бетенләй туктатылды.

Татар телендәге блоглар мөстәкыйль сайт рәвешендә дә очрый, әйтик, «Мөгаллим язмалары». Фәрит Вафинның шәхси сайты: педагогика, публицистика, иҗат». Шуның өстенә, Фәрит Вафинның аерым блогы да бар, ул анда видеолар элеп бара. Рөстәм Зарипов блогы, Булат Хаков сайты, Марат Кәбиров сайтында блог калыбын хәтерләткән «Куен дәфтәре» сәхифәсе бар, «Алма бөртеге язмалары», Сөмбел Гаффарова блогы, «Сөембикә» журналы сайтында редакция хезмәткәрләре һәм штаттан тыш хәбәрчеләрнең блоглары бар.

Татарча электрон көндәлекләрнең күбесе гомуми блог таләпләренә туры килә, әмма журналистика белән тиңләшердәйләре юк диярлек. Татарча блогларның байтагында комментарийлар калдыру мөмкинлеге бар. Сөмбел Гаффаровага һәр комментарий турында уң яктагы «Яңа фикерләр» баннерында хәбәр чыга.

Блогны, нигездә, һәвәскәрләр алып бара дигән фикер татар телендәге блогларда расланмый. Сөмбел Гаффарова – профессиональ журналист, Марат Кәбиров – язучы, Булат Хаков белән Мөнир Вафин – республика басмаларының даими хәбәрчеләре.

Көнел ачу функциясе «Алма бөртеге» язмаларында күзәтелә. Беренчедән, блогның исеме шаян рухта. Икенчедән, язмалар көнкүреш темасы. Уң яктагы сәхифәләр исемлегендә «кәмит» дип аталганы бар. Язмаларның исемнәре дә юмор-сатирага тартым. Әйтик, «Свежий карчык», «Кем мескен дә, кем өстен?». Мемуарлар функциясе өлешчә Марат Кәбировның «Куен дәфтәре»ндә чагыла.

Рафис Кашапов ике ресурста да блог алып бара, әмма «Тере журнал»дагысына игътибарны күбрәк бирә. Ике телдә дә яза, рус телендәге хәбәрләре күбрәк. Гомумән, язмалары милли темага һәм ил-дөньядагы сәяси вәзгыятькә карый.

Татар телендәге блоглар төрле рәвештә һәм төрле кыяфәттә эшләп килә. Аларның беренчел функциясе – татар теленең кулланылыш даирәсен киңәйтеп, милли телне яңа ясалыкта кулланып булуны раслау. Әмма бер төрле темаларга, әйтик, милләт, азатлык, педагогикага артык бирелеп, укучының канәгать булып бетмәве мөмкин. Шуңа да татар телендәге блогларны тематик яктан төрләндерү үзен аклаячак.

DARELFӨNYN университет
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир в.б. - Л.Р.Сабирова
Иҗат коллективы: И.Вәлиев, Р.Габдрахманова, А.Абдрахманова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Битка салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Басмырылыга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Фолиант» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Профсоюзная, 17в.